ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районынын**
**Тэмте авыл жирлеге Советы**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Совет Теньковского сельского поселения**

422824,Кама Тамагы муниципаль районы,
Тэмте авыл жирлеге, Октябрь урамы, 65

тел. 31-2-60

Камско-Устьинский муниципальный район,
Теньковское сельское поселение,
ул. Октябрьская, 65
тел. 31-2-60

## Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге башлыгының КАРАРЫ

**2020 елның 2 ноябрендәге** **№2**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Тәмте авылында гражданнар җыены үткәрү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә **КАРАР БИРӘМ**:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлегенең Тәмте авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2020 елның 18 ноябрендә 15.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлегенең Тәмте авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның 19 ноябрендә 15.00 сәгатькә билгеләргә.

***3.*** Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 2021 елда үзара салым кертүгә 300 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- **кышкы-җәйге чорда поселок эчендәге һәм урамара юлларны тәртиптә тоту;**
- **Урам утларын карап тоту;**
- **Тәмте авылында Беренче Май урамыннан Кызыл Тау урамына җәяүлеләр күперен ремонтлау;**
- **Тәмте авылында Комсомол урамында урнашкан коены ремонтлау.**

«РИЗА » «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм Тәмте авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге
башлыгы, Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте
авыл җирлеге Советы рәисе И. А. Зиновьев